# ШӘРЫК КЫЗЫ ЗӘРИНӘ

*сүзләре һәм көе – Шамил Сагаутдинов*

1. Көн бигрәк ямьсез иде,
Җил бигрәк әрсез иде:
Котырды, тинтерәтеп өрекләрне.
Ләкин бер кояш нуры
Болытны чыкты ярып.
Шул минутта очраттым юлда сине.

Яныңнан узып, нәрсәдер сизеп,
Әйләнеп, сиңа карадым.
Якты нурыңнан дәрт алган сыман,
Шул дәрткә кинәт тарыдым!

**Кушымта:**

Эх, Зәринә, Зәринә,
Шәрык кызы Зәринә!
Туймыйм һич, карап нурлы йөзләреңә!

Эх, Зәринә, Зәринә,
Кердең күңелем түренә!
Йолдызкаем, җан дускаем, Зәринә!

2. Айдай кыйгач кашларың,
Төндәй кара чәчләрең
Әсир иттеләр күңелемне мәңгегә.
Язмышка мин рәхмәтле:
Ничек соң илтте әле
Ул мине син яшәгән матур җиргә?

Нурлы илеңне, серле телеңне
Мин дә үз иттем, яраттым.
Еллар буена тик сине генә
Эзләгәнемне аңладым!

**Кушымта.**

**Восточная красавица Зарина**

Посвящается девушкам по имени Зарина.

*Помню: дождь угрюмо лил,*
*Ветер грозно в окна бил*
*И шумел, листву деревьев теребя.*
*Но однажды из-за туч*
*Вдруг пробился солнца луч,*
*В этот самый миг увидел я тебя.*

*И прошли дожди, стихли вдруг ветра,*
*И запели птицы в садах.*
*И увидел я чудный свет зари*
*В твоих нежных, милых глазах!*

*С той поры в душе моей*
*Наступила вдруг весна.*
*Имя той весны – Зарина, Зарина.*
*Эх, Зарина, Зарина,*
*Вся душа тобой полна,*
*Лишь тобой одной, Зарина, Зарина!*